СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2020 Баулы шәһәре № 14

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районының муниципаль милкендәге өченче зат хокукларыннан ирекле булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 256 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14нче статьясы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 73 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2020 елның 3 апрелендәге 256 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районының муниципаль милкендәге өченче зат хокукларыннан ирекле булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) озак срокка файдалануга бирү өчен (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча), шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына түләүле

нигездә милек итеп бирү (читләшү) максатларында билгеләнгән мөлкәт исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

15нче пункт белән тулыландырырга:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15. | 2нче номерлы бина «мәктәп» | 470,5 кв.м. 16:11:070202:140 | Татарстан Республикасы, Поповка авыл җирлеге, Югары Фоминовка авылы, Совет урамы, 56А | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Поповка авыл җирлеге |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин